# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасы Конституциясенә
үзгәрешләр кертү турында

<u>1 статья.</u> Татарстан Республикасы Конституциясенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 108 статьяның өченче өлешен төшереп калдырырга;

108 статьяның дүртенче өлешеннән "һәм вице-президентын" дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

108 статьяның дүртенче өлешен 108 статьяның өченче өлеше, дип санарга.

2. 109 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Татарстан Республикасы Президенты башка эш урынын били алмый, шулай ук Татарстан Республикасының һәм халык депутатлары җирле Советларының халык депутаты була алмый".

3. 115 статьяның беренче өлешендәге "вице-президентына" дигән сүзләрне "Премьер-министрына" дигән сүзләр белән алмаштырырга;

115 статьяның икенче өлешендәге "Татарстан Республикасы вице-президентына, ә бу мөмкин булмаса, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенә" дигән сүзләрне "Татарстан Республикасы Премьер-министрына" дигән сүзләр белән алмаштырырга.

<u>2 статья.</u> Әлеге Закон басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1995 елның 8 декабре
N 346